КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 18 июнь г.Казань № 435

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләре һәм махсус хәрби операциядә катнашу аркасында һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 ел, 20 октябрь, 1122 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 14 ноябрь, 1213 нче; 2023 ел, 20 март, 291 нче; 2024 ел, 9 апрель, 243 нче; 2024 ел, 20 май, 343 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның беренче абзацында «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында» сүзләрен «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында» сүзләрен «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында» сүзләрен «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым категорияләрдәге хәрби хезмәткәрләрнең һәм махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) гражданнарның балаларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» 2023 ел, 7 ноябрь, 1427 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 1 февраль, 53 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) расланган Аерым категорияләрдәге хәрби хезмәткәрләр арасындагы гражданның һәм махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) гражданнарның 18 яше тулмаган һәр баласына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

дүртенче абзацта «хәрби хезмәт узу турында контракт» сүзләреннән соң «һәм ихтыяри формированиеләрдә булу турында контракт» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацта «хәрби хезмәт узу турында контракт» сүзләреннән соң «һәм ихтыяри формированиеләрдә булу турында контракт» сүзләрен өстәргә;

тугызынчы абзацта «хәрби хезмәт узу турында контракт» сүзләреннән соң «һәм ихтыяри формированиеләрдә булу турында контракт» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин